СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №63 (7236) | 1 июнь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## УДАР ИКЕАЙЛЫК

**1 июньнән башлап районда чиста пар җирләренә органик ашламалар чыгару, ул басуларны эшкәртү буенча удар икеайлык игълан ителә. Аның барышында хуҗалыкларда барлык төр төяү, ташу техникасын бергә туплаган махсус отрядлар оештыру, печәнгә төшкәнче пар җирләренә оешканлык белән черемә ташу алып бару күздә тотыла. Бер үк вакытта бу эшкә тартылган механизаторларга түләүне яңадан карау, материаль кызыксындыру, туклану оештыру һәм башка чараларны да күрү зарури. Болар барысы удар икеайлыкны максатчан һәм нәтиҗәле үткәрергә мөмкинлек бирер.**

## Хуҗалык активы җыелышы

30 майда КПСС райкомының конференц залында хуҗалык активы җыелышы булып узды. Аның эшендә район Советы президиумы,район һәм шәһәр Советы башкарма комитетлары членнары,колхоз рәисләре, совхоз директорлары, шәһәр предприятиеләре, һәм оешмалары җитәкчеләре, авыл Советлары рәисләре, мәктәп директорлары һ.б. катнашты.

Активта чыгыш ясаган халык депутатларының район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов ТССР Югары Советының дүртенче сессиясенең йомгаклау утырышында каралган мәсьәләләргә, ТССР Президентын сайлау белән бәйле актив башкарасы бурычларга тукталды. Ул шулай ук язгы чәчүгә йомгак ясады, шикәр чөгендере эшкәртү һәм сирәкләү белән бәйле мәсьәләләрне, терлек азыгы хәзерләү, сугаруны нәтиҗәле оештыру, уракка хәзерләнү проблемаларын яктыртты. Терлекчелек проблемаларына тукталып сөт җитештерүне арттыру юлларын күрсәтте, юл төзелешен дәвам итү кирәклегенә игътибар юнәлдерде. Шәһәрнең кичектергесез эшләренә кагылып ул халыкны су белән тәэмин итү, кышка хәзерлек белән бәйле проблемаларга игътибар юнәлдерде.

## Бүген—Балаларны халыкара яклау көне



*Күк йөзендә кояш мәңге балкып торсын,*
*Чәчәкләрдән тәмле исләр аңкып торсын,*
*Сабыйларның күзләреннән нур сүнмәсен,*
*Сугыш дигән ут-ялкыннан җир көймәсен.*

## БЕР КОЛХОЗ ХӘБӘРЛӘРЕ

### Звено эштә

**Синдряков исемендәге колхоз.** Хуҗалык механизаторлары нәчү эшен уңышлы төгәлләделәр, әмма басуларда трактор гөрелтеләре тынмый, игенчегә мәшәкатьләр бетми әле. Хәзер пар җирләре органик ашлама чыгару өчен әзерләнә. Ә Николай Александрович Рассадин звеносы чөгендер плантациясендә үсемлекләр шытканчы тырмалау үткәрә. Әлеге звено чөгендер игү белән беренче ел гына шөгыльләнми, тәҗрибәсе җитәрлек. Алар һәр агротехник чараның үзвакытында сыйфатлы итеп башкарылуына зур әһәмият бирәләр. 150 гектарда шикәр чөгендере чәчүне дә 3 көндә төгәлләгән иделәр. Инде тырмалау үткәрүгә дә бик җаваплы карыйлар, көнлек нормаларын арттырып үтиләр.

**Н. ХРАМОВА.**

### Срогыннан элек

**Безнең колхоз бүгенге көнгә ит сату буенча алты айлык планны 189 процентка үтәде.**

**Узган еллардагыдан аермалы буларак, быел бәрәннәрне регуляр рәвештә үлчәп, артымнарны белеп, исәпләп тотабыз. Әйтергә кирәк, быел артым узган елдагыдан шактый яхшы: һәр бәрәннән артым 189 граммга җитә. Шулай ук һәр 100 сарыктан 96 бәрән алынды. Бу да узган еллардагы күрсәткечтән югары. Әлбәттә, бу үзгәрешләрнең сәбәпләре бар. Безнең сарыкчылык фермасында әлегә кадәр даими эшчеләр юк иде. Быел эшлекле коллектив җыйналды, сменалы эш җайга салынды. Халкы да күрәсең, эш өчен атлыгып йөрүчеләр туры килде. Җәйге чорда мактаулы көтүчеләребез Петр Помендеев һәм Анатолий Евлейкин турында мактау сүзләре әйтеп үтмичә булмый. Бу тырыш көтүчеләребез аркасында хайваннарыбыз көр һәм тук йөриләр дә.**

**В. ХРАМОВ.**

## Беренче көннәре

«Заветы Ильича» колхозының АВМ-0,65 витаминлы үлән оны әзерләү агрегаты үзенең беренче көннәрен эшли. Машинист Николай Шубин һәм аның ярдәмчеләре Иван Капитов белән Александр Погодин үзләрен киеренке хис итәләр. Терлекләргә азык әзерләү процессында һәрбер көн җаваплы бит. Никадәр күбрәк җитештерә алсаң, шулкадәр яхшырак. Шул принциптан читкә тайпылмыйча алар көненә 1,5—2 тонна үлән оны әзерлиләр.

Малларга күпьеллык үләнне МТЗ-80 тракторында КПИ печән чапкычы белән тракторчы Владимир Исаев чаба.

**Н. ЕРХОВ,**
баш бухгалтер.

## Савым арта

Җәй —мул сөт чоры. Кузнецов исемендәге колхозда җәйге лагерьларга күчкәч, көнлек савым да арта башлады. Савучы Нина Глухова группасыннан көнгә элекке 270 килограмм урынына 333 килограмм сөт савуга ирешә.

Галина Кулагина, Алевтина Арбузова кебек уңган савучылар да көнгә группаларыннан уртача 280—287 килограмм сөт савалар. Бу күрсәткечләрдә, әлбәттә, Анатолий Бойков, Юрий Савельев, Александр Савельев кебек тырыш көтүчеләрнең дә өлеше зур.

Ирешелгәннәр әле чик түгел, терлекчеләр җәйге мөмкинлекләрдән тулырак файдалану өчен тырышалар.

**Н. ЖИРНОВА.**

## Сайлаучылар игътибарына!

### Киткән депутатлар урынына сайлау үткәрелә

«Татарстан ССРның халык депутатларын, җирле Советларның халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан ССРның 54 нче статьясы нигезендә халык депутатларының Нурлат шәһәр Советы башкарма комитеты карары белән 11 нче һәм 21 нче шәһәр сайлау округларыннан киткән депутатлар урынына 1991 елның 12 июнендә сайлаулар үткәрелә.

Сайлаулар 11 нче сайлау округы буенча 3 нче номерлы урта мәктәптә, 21 нче сайлау округы буенча «Нефтьчеләр» клубында уздырыла.

Округларга түбәндәге урамнар керә: 11 нче сайлау округына—Циалковский (7, 9, 11 нче номерлы торак йортларыннан кала), Маяковский, Тукай, Карбышев, Линейная (36, 37, 38, 38а, 38б, 38в, 38г номерлы йортлары) урамнары, 21 нче сайлау округына—Победа, Космонавтлар урамнары, Козлов урамының 1 нче йорттан алып 11 нче номерлы йортлары керә.

Халык депутатларының шәһәр Советына халык депутатларына кандидат итеп 11 нче сайлау округы буенча Октябрь райпосының азык комбинаты хезмәт коллективыннан 1958 елда туган, азык комбинатының клиндер-кондитер әйберләре цехы эшчесе Андреева Нина Алексеевна, 21 нче сайлау округы буенча, Октябрь район Советы башкарма комитетының күптармаклы производство предприятиесе хезмәт коллективыннан 1957 нче елда туган, МПП начальнигы Фәрит Исламович Гайнуллин күрсәтелде.

**Шәһәр сайлау комиссиясе.**

## Күңелле булды аланда

Чәчү бетү авылда элек-электән үк бөтенхалык бәйрәме булган. Бу традициядән без агымдагы елда да читтә калмадык.

Иртән үк репродуктордан музыка агылды, әйтерсең лә ул халыкны бәйрәмгә ашыктыра иде. Авыл артындагы киң мәйданда Фома һәм Егоркино РТП-сы кибетләре урнашты һәм сатучылар киштәләргә инде үзләренең товарларын төзеп тә куйдылар. Янәшәдәгенә камыр ашлары пешерүчеләр. Көннең кояшлы, матур булуы да бәйрәм хуҗалары, кунаклар, күрше колхозлар хезмәтчәннәре күңеленә хуш килде.

Колхоз председателе В. Ф. Булатов, баш агроном Л. В. Казаков язгы кыр эшләре барышына анализ ясадылар, игенчеләр алдында торган бурычларга тукталдылар, механизаторларны җиңү белән тәбрикләделәр. Ярыш нәтиҗәләре белән башлангыч партоешма секретаре В. А. Паруков таныштырды һәм җиңүчеләргә акчалата бүләкләр тапшырды. Алдынгылар арасында В. А. Абрамов, Ф. Н. Краснов, С. Д. Еремеев, В. Н. Яковлев (II бригада), Ю. П. Туймешев, Г. Е. Акмуллин, В. П. Туймешев (I бригада) бар. Авыл хуҗалыгы профессиональ-техник училищесы курсантлары А. Улаев, В. Соловьев, Ф. Соловьев, А. Абрамов, А. Еремеев, А. Акмуллин һәм башкаларга да язгы чәчүдә әйбәт эшләгәннәре өчен акчалата бүләк бирелде.

Бәйрәм программасы күпкырлы булды. Ат-спорт ярышларында «Москва» колхозы чабышкылары да катнашты. Беренче урынны «Буян» кушаматлы ат алды. («Москва» колхозы), җайдагы Фәрит Җәббаров; икенче «Запасная» кушаматлы ат, җайдагы Валерий Хвасев, юртаклардан «Приказ» кушаматлы тай лидер булды, җайдагы Н .М. Сендюков.

Шул ук вакытта «Большевик» һәм «Заря» командалары футбол буенча дусларча очрашу үткәрделәр. Безнең егетләр 2:1 исәбенә оттылар.

Бәйрәм татар милли көрәше белән тәмамланды.

Лотерея уеннарында исә промышленность товарлары гына түгел, тере дуңгыз балалары, бозаулар, тайлар оттылар. А. И. Паруков бәхетлеләрдән булды, ике яшьлек тай отты. И. П. Семенов һәм И. В. Савгачев икесенә аерым-аерым 50 шәр килограммлы үгез алдылар.

Бәйрәм көне буена дәвам итте. Халык рәхәтләнеп күңел ачты.

**Г. ЕРЕМЕЕВ,**
«Большевик» колхозы.

# ТАТАР УЯНДЫ

Республикабызның башкаласы Казанда соңгы көннәрдәге шаулы вакыйгаларны легенда ясап сөйләрлек. Анда безнең корреспондентыбыз С. ХӘЙРУЛЛИНА да катнашты. Түбәндә—әлеге данлы көннәр күренешләреннән кыскача репортаж.





Казанлылар әйтә: бу хәл 30 нчы августтан бирле дәвам итә, диләр. Әмма Ирек мәйданында 26 нчы, 27 нче май көннәрендә булган җанлылык, бердәмлеккә, андагы көчкә алар үзләре дә таң калалар.

Татар уянды—ниһаять, бу сүзне авыз тутырып әйтергә була иде. Татар уянды, үз теле, үз җире, үз мәдәнияты, ирегe өчен, азатлык өчен бер йодрыкка тупланып мәйданга чыкты. Ул көннәрдә мәйдан күп вакыйгалар шаһиты булды. Ул көннәрдә милләт мәнфәгатен үзенең төп мәнфәгате итеп санаган 19 кеше ачлык игълан итеп, бер таләпне куйды: Татарстан җирендә РСФСР Президентын сайлауга юл куймаска! Бу хәрәкәтнең лидеры ТССР халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова ачлык игълан итүенең 14 нче көнен авырлык белән кичерде, мәйдан аның ныклыгы каршында баш иде. Ул көнне мәйдан милли әләмнәр, Сәйдәш маршы, Тукайның «Туган теле», намазга утырган мөгътәбәр карт-карчыклар догасы дулкынында азатлык, ирек көтеп күзләрен ресcком, ТССР Министрлар Советы бинасына текәде. Һәр ТССР халык депутаты халык оештырган тере коридор буенча шул наказны йөкләтеп әлеге бинага озатылды. Митинг көне буе дәвам итте. Чыгышлар күп, чыгышлар төрле. Аларның соң чиккә җиткән ачулылары да, артык таләпчәннәре дә, артык бунтарьлары да бар.

Аһ, акылны җуймыйсы, суверенитет өчен барган изге көрәшне милли төсмер белән генә чикләүгә юл куймыйсы иде. Мәйданда, шөкер, шуны аңлаучылар, шуны алга сөрүче алдынгы көчләр җитәрлек. Аларга автобус белән Чаллы шәһәреннән, Түбән Камадан, гомумән, илебезнең ничәмәничә төбәгеннән хәтта Себер, Ташкенттан кадәр килгән милләттәшләребез кушыла. Соңрак, 28 майда ТССР Югары Советы рәисе М. Ш. Шәймиев республика, үзәк газеталары, радио-телевидение журналистлары белән очрашу вакытында әлеге хәлләрне Татар иҗтимагый үзәге һәм «Иттифак» фиркасе тарафыннан оештырылган нәрсә дип кенә бәяләде. Әмма мәйдан шаһит: татар уянды. Әлегә бәлки бу артык эмоциональ, артык кискен, бераз бунтарь да хәрәкәттер. Аны һәрьяклап хуплаудан без дә ерак торабыз. Әмма әлеге вакыйгалар, күренешләр бер нәрсәгә ышанычны ныгытты: моннан соң халкыма күрсәтмә буенча холык-фигыленә ят, мәнфәгатенә кирәксез акыл көчләп тага алмаячаклар; моннан соң аның җирен, аның байлыгын теләсә ничек сарыф итә алмаячаклар. Аның чит сүз, чит җыр кабатлар чаклары да узган, ул үз моңын, үз көен үз фигылен яңарта. Мәйдан шаһит: татар уянды. Хуплап, якты өмет баглап сәламлик.

Рәсемнәрдә: «Безгә Рәсәй байрагы кирәкми, менә ул—безнең әләмнәр!»—дип, айлы-йолдызлы милли әләмне әллә кайдан күренерлек итеп мәйданга беркеттеләр.

2. 14 нче көн ачлыкта торган Фәүзия Бәйрәмованы халык кәнәфигә утыртып, кулына күтәреп ТССР Югары Советы сессиясенә озатты. Аның юлында, кызыл, ал лаләләр, канәфер чәчәкләре сибелеп калды.

3. Тәртип саклаучыларны мәйдан «өзелеп сөйде» дип булмый. Юкса, аларга эш аз-азлап чыга торды.






## Игенчеләргә ярдәмгә

Һәр килгән яз башкаларыннан ни белән булса да аерылып тора, авыл хезмәтчәннәре өчен күп мәшәкатьләр тудыра.

«Агропромхимия» производство берләшмәсе механизаторлары игенчеләргә ярдәмгә ашыгалар. Язгы юл өзеклеге вакытында алар кыска срокларда үзләренә беркетелгән бөтен транспортка, тагылма җайланмаларга техник карау үткәрәләр, машиналарның буяулары яңартыла, күрсәтелгән төзексезлекләр бетерелә. Шуннан соң берләшмә эшчәннәре, алдан килешү буенча кичекмәстән хуҗалыклар басуларына ашлама кертү эшләренә керешәләр. Дөрес, бу эш кыш көне дә тукталып тормый, чөнки 1991 ел уңышына күздән үк нигез салына башлый бит.

Быелгы яз да кыр хезмәтчәннәре өчен бер дә уңайлы килмәде. Көчле җилле, карлы-яңгырлы һава торышына өстәп,чәчү кырларының тигез өлгермәве дә зур кыенлыклар тудырды. Чәчү барышында техника белән маневр ясап культивация, уҗым тукландыру эшләрен дә бергә алып барырга туры килде. Шулай ук эш барышында планга төрле төзәтмәләр дә кертелде. Берләшмәгә караган комплекслы звено хезмәтчәннәре үзләренә беркетелгән дүрт РУМ-8, ике УРАЛ автомашинасы, дүрт ПРТ-10 тараткычы белән һәр көнне 60—70 эр гектар хуҗалык басуларын известьладылар, 2100 гектар мәйданны ашладылар. Звено ярты еллык йөкләмәләрен 1 июньгә үтәүне максат итеп куйган иде.

Тракторчылар Нәзир Кәримов, Александр Убамзаров, Ислам Курамшин, Минталип Таҗиев, шоферлар Якуб Бәширов, Николай Савельев, төяп торучылар Николай Петров, Рамил Вәлиев көнлек нормаларын 110—120 процентка арттырып үтиләр.

Звенога, күп еллар эшләү дәверендә зур тәҗрибә туплаган Хай Авзалович Яһудин җитәкчелек итә.

Хәзерге вакытта звено членнарының төп максаты —басуларны известьлауны сыйфатлы итеп башкару.

Н. ГАФУРОВ.

Кадерле редакция! Шәһәребезнең мәктәп урамы үзенең яшеллеге белән сокландыра иде. 25—30 еллык тупыл агачлары күкрәп үсә иде анда.

Хәзер Ашхабадта яшәүче, 1947 нче елгы кызым Гөлшат (ул 2 нче мәктәптә укыган иде) кунакка кайткан саен шул үзләре утырткан агачларны күрергә китә иде. «Үзең утырткан агач та кадерле икән, әни»,— дия иде ул.

Көннәрдән бер көнне шушы урамнан үтәргә туры килде һәм исем китте, әлеге мәгъруур тупылларның рәте сирәгәйгән, анда кеше биеклеге калдырып киселгән кәүсәләр утыра һәм урыны-урыны белән төпләр күренә иде.Бу вәхшилеккә исем китте. Кайсы явызының эше бу? Ничек шундый эшкә куллары барган? Гаепләләргә чара күрелсен иде.

70 яшьлек Диләфкәр әбиегез Сатдарова.
Норлат шәһәре.



Хөрмәтле Диләфкәр апа!

Бу хакта безгә телефоннан шалтыратучылар да, үзләре килеп рәнҗүләрен сөйләүчеләр дә аз булмады бу көннәрдә. Чынлап та әлеге урамда күккә ашкан 36 төп тупылны шәһәр Советы рәисе, халык депутаты М.М. Фәррахов боерыгы белән кисеп аударганнар. Шәһәребезнең дүрт дистәгә якын «яшел баһадирына» каршы көрәшкә чыгарлык кыюлыгы булгач, бу депутатның «зур» эшләр башкарачагына өметләник инде без. (Кисеп ташланган ботак-сатакның гына әле һаман да җыештырылмыйча урамда аунап ятуы безгә аңлашылмый).

Кызыгыз дөрес әйткән булган, Диләфкәр апа.Үзең утыртсаң гына кадерле шул ул агач. Үзе утыртып карамаган кеше аның кадерен каян белсен...

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

Рәсемдә: Мәктәп урамындагы һәлак булган баһадир тупыллар...

Н. Азизов фотосы.




**Кадерле әтиебез Хөббулла Шәрифулла улы Шәйдуллинны 55 яше тулу көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Сәламәтлек, озын гомер һәм сөенечләр телибез.**

**Тормыш иптәше, уллары, киленнәре, оныклары.**

---

**Югары Норлат авылында яшәүче кадерле туганым Мәрьям кызы Яруллинаны 50 яшь тулу уңае белән кайнар котлыйм, аңа шатлыклы озын гомер, нык сәламәтлек, бәхет, тыныч тормыш телим.**

**Сәламәт бул, гел шат яшә,**
**Бәхет кунсын күңел түренә**
**Барыбызга канат, терәк булып**
**Талмый атла гомер түренә.**

**ФЛҮЗӘ. Пермь өлкәсе.**

# ИКЕ АЯКЛЫ ЕРТКЫЧ

(Ахыры.Башы 57 нче санда).

...«Ашыгыч ярдәм»дә чираттагы дежурлык врач өчен ярыйсы гына мәшәкатьле була, машинада бәбиләгән хатынны үлемнән коткарырга туры килә.Арыган, дулкынланган Куликка хатынның туганнары зур рәхмәтләр укыйлар. Һәм, бик күтәренке кәеф белән сменасын тапшырып, ул алдан ук билгеләнгән адрес буенча 75 яшьлек Ч.га юнәлә. Чакырмаган көе иртәнге сигезләрдә үк килеп кергән врачка тегесе гаҗәпләнә. «Дежурлыктан кайтып килешли сезне искә төшердем әле менә,—дип аңлата Кулик. —Хәлләрегез ничек икән дим». Үзен ни көткәнен башына да китермәгән бичара карчык врачка рәхмәтләр укый. Аның кан басымын үлчәгәч, Кулик башын чайкап куя: начар, янәсе, укол кирәк. Икеләтә дозадагы аминазин тәэсирендә карчык шунда ук йокыга тала... Моңа хәтле корбаннарын гел буып үтерә торган явыз бу юлы беренче тапкыр пычак куллана. Ч.ны үтергәннән соң бераввык хисләрен аңлый алмый тора: буып үтерүе рәхәтрәкме, әллә суепмы? Моны аңлар өчен ул кабат «эксперимент» ясап карарга уйлый. Һәм шприцлар, дарулар белән бергә дипломатында һәрчак пычак йөртә башлый. Корбанны озак эзләргә туры килми: 66 яшьлек Л. үзе аны өенә чакыра. Кулик ул яшәгән йорт тирәсендә кар көрәп торганда (урам җыештырып акча эшләгән чагы була) күреп ала да, кайчандыр үзен дәвалаган врач икәнен танып, сәламәтлегеннән зарлана. Өенә кереп тикшереп каравын үтенә. Кулик сөенә-сөенә дипломатын алып килергә йөгерә. Сыналган уколын ясый да, пычагын тартып чыгара.

Бичараны ул эксперимент ясаучыларга хас эшлеклелек белән үтерә. Тәненең төрле җирләренә пычак йөзен сабына тикле кадап-кадап карый. Идән кан белән тула. «Эшен» бетергәч, эзләрен югалту өчен шактый җыештырырга туры килә. Орышына-сүгенә сөртә ул идәнне: өйгә ашыгасы бар бит, диабеттан җәфаланучы әнисенә кичә приступ булган иде, алла сакласын, бер-бер хәл була күрмәсен...

Суд амбулатория шартларында гына үткәрелгән психиатрик экспертиза беләнгенә канәгатьләнми һәм Куликны стационарга урнаштыралар. Иркутск һәм Мәскәүнең иң зур белгечләре аны берничә ай буена күзәтәләр. Әмма никадәр генә тикшермәсеннәр, Куликның акылында бернинди дә тайпылыш тапмыйлар —тулысынча сау-сәламәт.

Коточкыч җинаятьләрен кылып йөргәндә ул берничә тапкыр эләгә язып та кала. Аны берничә кат исән калган корбаннары таный, милиционерлар һәм дружиначылар тоткарлый, соңрак үле килеш табылган бала белән бергә йөргәнен күрүчеләр табыла, әмма һәрчак Кулик судан коры чыга. Шулхәтле интеллигентлы врачтан шикләнергә берәүнең дә башына килми, һәр очракны ялгыш туры килү генә дип уйлыйлар.

Ничек кенә сак кыланмасын, азгын җенси дәрте аны берничә тапкыр тозакка да кертә, бары ишеген генә ябасы кала. Әмма...Куликның сөяркәсе Ф. биргән күрсәтмәләрдән: «Мин кухняга киткәндә ул еш кына улым янына ятып кала иде. Улым соңыннан зарлана: абый минем бөтен җирләремне тота, ди. Мин, яратып кына иркәлидер, дип үземне тынычландыра идем». Куликның үз күрсәтмәләреннән: «Ике тапкыр үземнең өч яшьлек улымны көчләргә тырышып карадым, әмма тотылудан куркып тыелып калдым». Ирина Федоровна, Куликның хатыны: «Улым әтисенең аңа бәйләнүенә, ят җирләреннән тотуына зарлангач, мин Василийдан бу хәлне аңлатып бирүен таләп иттем. Тик, бот арасына чыккан чуанын гына даруладым бит, дигәч, ышандым инде».

Суд-психиатрия экспертизасы актыннан: «Шул көннән соң, үз улларын күрүдән җенси дәрте уянган саен, ул киенеп урамга чыгып китә һәм ялгыз гына йөрүче балаларны аулый башлый».

...Аның чираттагы корбаны уйнап йөрүче дусларын читтән генә басып күзәтеп торучы бәләкәй малай була. Яңа җинаять бөтен шәһәрне тетрәндерә, аның турында һәр җирдә сөйлиләр. Куликка туган-тумачасы һәм танышлары тарафыннан шактый гына психик атака кичерергә туры килә. Ерткычларча җәфалап үтерелгән бала турында аңа беренче булып коты алынган хатыны кайтып сөйли. «Кара инде, ходаем, бу хәтле явызлыкны эшләү түгел, күз алдына китерүе дә коточкыч бит!..» Больницада ятучы әнисенең хәлен белергә килгәч, анысы да кызарынган күзләре белән улына төбәлә: «Син ишеттеңме? Хәер, ишеткәнсеңдер инде, монда булып монда бөтен палата шаулый... Нинди ана тудырды икән шул кабәхәтне, ходаем?!» Куликның керфеге дә селкенми, тыныч тавыш белән әнисен юата: «Аның өчен дә борчылма инде, сиңа дулкынланырга ярамый бит».

Элгәреннән бераз алдарак кына ул акылга зәгыйфь балалар укый торган ярдәмче мәктәпкә ярты ставкага врач булып урнаша. Конфетлар биреп, башларыннан сыйпап балаларның мәхәббәтләрен яуларга да керешә. Әгәр әлеге ашханәдә эшләүче хатын-кызларның сизгерлеге, куркусызлык күрсәтүе, узып баручылар арасында өлгер һәм кыю егетләр туры килү аркасында эләкмәсә, тагын нинди генә йөрәк өзгеч явызлыклар кылмас иде ул!

Ничек итеп шул хәтле явыз, коточкыч җанвар булып әверелгән соң бу бәндә?

Куликның апасы Людмила Михайловна сөйли: «Гаиләдә Василийга карата үзенә бертөрле мөнәсәбәт иде. Аны иркәләделәр, теләсә нәрсә эшләргә рөхсәт иттеләр. Һәр шуклыгын кичерделәр. Бу мөгамәләне ул бик тиз аңлап алды һәм үз-үзен генә яратучы, каты бәгырьле булып үсте».

Бала чагында Кулик песиләр асарга бик яраткан икән. Бик иртә секс белән кызыксына башлаган, иртә өлгергән. Аның әтисе, мәрхүм профессор да таш бәгырьле, каты куллы, хатын-кызларга бик һәвәс булуы белән аерылып торган икән.

Куликның үзе биргән күрсәтмәләрдән: «Миңа хатын-кызларның тотнаксызлыгы тәэсир иткәндер, дип исәплим. Әле мәктәптә укыганда ук бер кыз белән йоклаган идем. Соңыннан аның инде дистәдән артык кеше белән булганлыгын белдем. Студент вакытта колхозга эшкә баргач, ирдәге бер яшь кенә хатын белән таныштым. Ул мине бик күп бозыклыкларга өйрәтте. Ресторанда танышкан икенче бер хатын гомосексуалист ире йоклап торган ир-атлар белән үзенең дә булуы турында сөйләде. Соңгы елларда минем берьюлы 20-гә якын сөяркәм бар иде. Хатын-кызлар мине туйдырдылар. Мин инде алардан канәгатьләнү алалмый башладым...»

Кеше кыяфәтле бу ерткычны формалаштырган сәбәпләрдә казынудан туктасак та ярыйдыр. Эш анда гына түгел, иң куркынычы —безнең шушы Кулик ишеләр алдында чарасызлыгыбыз. Хокук саклау органнарында җинаятьчене үз вакытында фаш итәрдәй чын профессионаллар аз. Милиционерлар, тикшерүчеләр хезмәтендә экономияләү: аз эш хакы, көчсез техник база, һич канәгатьләнмәслек хезмәт һәм көнкүреш шартлары аркасында милициягә очраклы кешеләр күп эләгү нәтиҗәсе бу!

...Кулик Василий Сергеевич РСФСР һәм УССР җинаятьләр кодексларының дүрт статьясы нигезендә үлем җәзасына хөкем ителә.

Бер кешене дүрт тапкыр үтереп булмый, әлбәттә. Хәер... бу ерткыч өчен дүрт җәза да аз булыр иде.

**«Совет милициясе» журналыннан Р. МӘГЪСУМОВА кыскартып тәрҗемә итте.**

---

**Октябрь МСОсының төзелә торган чистарту корылмаларына ашыгыч төстә каравылчылар кирәк. Хезмәткә түләү 120 сум, өстәмә мәгълүматларны 2—12—44, 2—14—75 телефоны буенча белергә мөмкин.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Асия МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУЗЯХМЕТОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 63. Тираж 3411.**